**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының**
**Югары Шепкә авылҗирлеге Советы**

**КАРАР**

**№93** **27.06.2023ел**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Шепкә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында» 2014 елның 13 февралендәге 124номерлыЗәй муниципаль районыЮгары Шепкә авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон,«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 06апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә,Зәй муниципаль районының Югары Шепкә авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Шепкә авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге Советының 13.02.2014 № 124 карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәнең 19 статьясындагы 3 өлешенә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы башлыгы (Рәис)»сүзләре белән алыштырып үзгәреш кертергә.

2. Карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Совет рәисе** **Л.М.Камалиева**